| ГЛАВА<br>Терсинского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Тирсә авыл җирлеге<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |
|---|---|

28.10.2025 Тирсә авылы № 5

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тирсә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

Гамәлдәге законнар нигезендә, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Законның 35 статьясына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тирсә авыл җирлеге башлыгы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тирсә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынының 1нче этабын 2025 елның 14 ноябрендә 11сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тирсә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынының 2нче этабын 2025 елның 14ноябрендә 13әгать 00 минутка билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тирсә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынының 3нче этабын 2025 елның 14ноябрендә 15сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тирсә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынының 4нче этабын 2025 елның 14ноябрендә 18әгать 00 минутка билгеләргә.

3. Халык исемлеген бүлүне территориаль билге буенча башкарырга:

-1 этап: Көнчыгыш урам, Көнчыгыш тыкрык , Яшьләр урамы, Беренче Май урамы, Мәктәп урамы, Елга аръягы урамы, Яр буе урамы, Тау урамы.
-2 этап: Үзәк урам;

-3 этап: Басу урамы, Дуслык урамы, Тынычлык урамы, Болын урамы, Күл урамы, Бакча урамы, Совет урамы, Хезмәт урамы.

-4 этап: Вокзал урамы.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тирсә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, (I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекчеләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәүче ата-аналары, ире яки хатыны, балигъ булган балаларыннан) башка), 2026 елда үзара салым акчасын 750 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә, куллануга ризамы?

1. Торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (таш сатып алу һәм җәю) һәм автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар);
2. Торак пункт территориясен төзекләндерү (авария хәлендәге һәм корыган агач-куакларны кисү, чүп үләннәрен чабу, юлларны кардан чистарту, грейдер белән тигезләү, тракторны, янгын сүндерү машинасын карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү; ягулык-майлау материаллары, трактор һәм машина өчен запас частьләр, өстәмә җиһазлар сатып алу,

«РИЗА» «КАРШЫ»

Аерым мәсьәләләр буенча экономия ясалган очракта авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Тирсә авылы, Үзәк урам, 163нче йорт, авыл мәдәният йортында гражданнар җыенын уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тирсә авыл җирлегенең башкарма комитетына җыенны оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru)

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы И.И.Закиров